# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**28.03.2024 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлеге башлыгының 14.03.2024 ел № 6 "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыенының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 29.11.2023 ел № 2 гражданнар җыеннары карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында"29.11.2023ел № 1 "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каранторак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында" Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 29.11.2023 ел № 2 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Николаевка авыл җирлегенең Рус Каран торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 29.11.2023 ел № 1 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны киләсе редакциядә бәян итергә:

«1) Рус Каран торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (грейдирлау, килешү буенча эш өчен түләү);

2)Рус Каран торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су чыгару системасын, су күтәрү манарасын, скважинаны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (скважина өчен тирәнлек насосы сатып алу);

3) Рус Каран торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (энергияне саклый торган яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ремонтлау».

2.Әлеге карарны Николаевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Николаевка авыл җирлеге
башлыгы урынбасары В.А. Липин